ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

27.05.2022 № 673

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Алабуга шәһәре территориясендә урнашкан каты коммуналь калдыкларны җыю мәйданчыкларының реестрын һәм урнашу схемасын раслау турында» 2021 елның 24 мартындагы 375 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль законның 13.4 статьясындагы 4 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар җыю урыннарын (мәйданчыкларын) төзекләндерү һәм аларның реестрын алып бару Кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 31 августындагы 1039 номерлы карары нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Алабуга шәһәре территориясендә урнашкан каты коммуналь калдыкларны җыю мәйданчыкларының реестрын һәм урнашу схемасын раслау турында» 2021 елның 24 мартындагы 375 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Алабуга шәһәре территориясендә урнашкан каты коммуналь калдыклар җыю урыннары (мәйданчыклары) реестры» 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә 253-254 пунктлар белән тулыландырырга:

| № | Каты көнкүреш калдыкларын җыю урыннары (мәйданчыклары) турында белешмәләр | Каты коммуналь калдыклар җыелу урыннарының (мәйданчыкларының) техник характеристикалары турында белешмәләр | | | | Каты көнкүреш калдыкларын җыю урыннарының (мәйданчыкларының) милекчесе турында белешмәләр | Мәйданчыкта саклана торган каты көнкүреш калдыклары белән эш итү чыганагы турында мәгълүмат |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Капламалар турында мәгълүмат | мәйданы | Контейнерлар күләме | Контейнерлар (бункерлар) саны | | |
| 253 | ТР, Алабуга шәһәре, Мәрҗани урамы, 28В йорт | бетон катлам | 12 м2 | 1,1 м3 | 6 | Шәхси эшкуар Данилова Марсила Мансур кызы, ТР, Алабуга шәһәре, Стахеев урамы, 20 йорт, кв.1 ИНН (салым түләүченең шәхси тәңгәлләштерү саны) 164601452031 ОГРИП (шәхси эшкуарның төп дәүләт теркәве номеры) 309167425100151 | «Танар» ҖЧҖ (шәхси клиника) «Тандер» АҖ («Магнит» кибет); ТР, Алабуга шәһәре, Мәрҗани урамы, 28В йорт |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 254 | ТР, Алабуга районы, «Алабуга» сәнәгать мәйданчыгы, 11 урам, 26 корпус | бетон катлам | 9 м2 | 1,1 м3 | 2 | Татарстан Республикасы, Алабуга районы «АлАЗ ЖБ» АЖ; ИНН (салым түләүченең шәхси тәңгәлләштерү саны) 1646016818 ОГРН (төп дәүләт теркәү номеры) 1051655002761 «Алабуга» сәнәгать мәйданчыгы, 13 урам, «АлАЗ җитештерү берләшмәсе» ААЖ нең 6 нчы җитештерү базасы | «АлАЗ-Транс» ҖЧЖ ИНН (салым түләүченең шәхси тәңгәлләштерү саны) 1646031301 ОГРН (төп дәүләт теркәү номеры) 1111674004287 ТР, Алабуга районы, «Алабуга» сәнәгать мәйданчыгы, 11 урам, 26 корпус Административ, офис объектлары |

2. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов